Республика Татарстан
Глава Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423647, Менделеевский район, с. Тураево,
ул.Центральная, д 11а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Башлыгы

423647, Менделеевск районы, Турай авылы,
Үзәк урамы, 11а

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm

2022 нче елның 5 декабрендәге 1 нче номерлы карары

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең Татар Ахтиялы
авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча халык
җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 15 декабрендә 12 сәгать 00 минутка Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен урыны итеп татар Әхтиялы авылы, Центральная урамы, 9 Б адресы буенча Татар Әхтиялы авылы мәдәният йортын билгеләргә .
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау:
   «Сез 2023 елда Менделеевск муниципаль районының Татар Әхтиялы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юлларга ризамы:

- урамнар, номерлар исемле аншлаглар сатып алу һәм һәр йортка урнаштыру;

- колонкаларга материаллар сатып алу һәм стенд төзү.

“РИЗА”                    “КАРШЫ"

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru " Турай авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы            А. М. Рәхимова